ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06 06 2022 г. № 345

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 23 октябрендә кабул ителгән 925 номерлы карары белән расланган стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру шартнамәсен төзү хокукына торглар әзерләү һәм үткәрү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт җайга салуы нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент үткәрү хакында» 2018 елның 27 ноябрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 23 октябрендәге 925 номерлы карары (3 нче кушымта) белән расланган стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру шартнамәсен төзү хокукына торглар әзерләү һәм үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 бүлегендәге дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гариза бирүче (претендент) – тәкъдим ителгән шартларда торгларда катнашу өчен гариза биргән, «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы юридик зат, шәхси эшмәкәр яки физик зат;»;

8.2. пунктта:

дүртенче абзацта «шәхси эшмәкәр турында мәгълүматлар» сүзләреннән соң «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик зат» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацта «юридик зат яисә шәхси эшмәкәр» сүзләрен «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы юридик зат, шәхси эшмәкәр яки физик зат» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация системасында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисади үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм итү идарәсе башлыгы А.Ф. Гарифуллинга йөкләргә.

Җитәкче Р.Х. Муллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА * РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МКУ «ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ» МКУ * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874